Татар гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен
татар теленнән мәктәп олимпиадасы биремнәре җаваплары
2017-2018 уку елы
6 нчы сыйныф

Үткәрү вакыты – 60 минут.
Максималь балл – 42.

I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Сүзләрнең барысында да [w] әйтелә торган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) бау, кавын, бавыр, Вил
ә) авыз, вакыт, тавык, су
б) телевизор, вагон, автор, ваза
в) Галиев, авыл, савыт, тау

2. Җөмләдәге ирен гармониясенә буйсынган сүзләр санын билгеләгез. ***(2 балл)***

Эчә торган төче су планетадагы бар сулыкларның нибары ике генә процентын тәшкил итә. (Г.Бәширов)

а) 1 ә) 2 б) 3 в) 4

3. Җөмләдәге алынма сүзләр дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Әни өстәлгә мичтән яңа алынган түм-түгәрәк ипи китереп куйды. (Ш.Маннапов)

а) әни
ә) өстәлгә
б) мичтән
в) өстәлгә, мичтән

4. Омонимнарның төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Марат йөгерү ярышында алтынчы булып килде. – Бүген без алтынчы һөнәре турында сөйләштек.

а) саф лексик
ә) омоформа
б) омофон
в) омограф

5. ***Кулы бии*** фразеологизмының мәгънәсе дөрес аңлатылган рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) бик оста бии торган

ә) алдакчы, ялагай

б) бик уңган, җитез

в) мактанчык

6. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән кисәкчәнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Табигать йокысыннан уянырга әзерләнә ***генә*** *иде әле.* (Ф.Садриев)

а) икеләнүне белдерә торган

ә) раслауны белдерә торган

б) көчәйтүне белдерә торган

в) чикләүне белдерә торган

7. Калын хәрефләр белән бирелгән исемнәрнең үзенчәлекләрен билгеләгез. ***(2 балл)***

Байлыгым *булмаса,* ***намусым*** *бар.* (Мәкаль)

а) баш килештә, I зат тартым белән төрләнгән, берлек санда

ә) иялек килешендә, I тартым белән төрләнгән, берлек санда

б) төшем килешендә, II тартым белән төрләнгән, күплек санда

в) баш килештә, тартым белән төрләнмәгән, берлек санда

8. Җөмләнең төре дөрес күрсәтелгән рәтне билгеләгез. ***(2 балл)***

Хәзер матур кошлар арасында да иң матуры диләр икән үзен! (Һ.Андерсен)

а) хикәя

ә) сорау

б) боерык

в) тойгылы

II. Теоретик бирем.

Сингармонизм законы турында белгәннәрегезне языгыз. ***(10 балл)***

III. Иҗади бирем.

Сузык аваздан башланган сүзләрдән генә торган “Алтын көз” дип аталган темага 8 җөмлә языгыз. ***(16 балл)***